ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 162 2017 елның 15 марты

# Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 8 июнендә кабул ителгән 968 номерлы «Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан Түбән Кама шәһәре территориясе өстендә авиация эшләре, парашют сикерүләре башкаруга, бәйле аэростатлар күтәрүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2010 елның 18 ноябрендәге 1491 номерлы карары нигезендә, карар бирәм:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 8 июнендә кабул ителгән 968 номерлы «Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан Түбән Кама шәһәре территориясе өстендә авиация эшләре, парашют сикерүләре башкаруга, бәйле аэростатлар күтәрүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына кертелә торган үзгәрешләрне расларга.

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

А.Г. Сәйфетдинов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2017 елның 15 мартындагы
162 номерлы карары белән расланган
кушымта

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 8 июнендә кабул ителгән 968 номерлы «Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан Түбән Кама шәһәре территориясе өстендә авиация эшләре, парашют сикерүләре башкаруга, бәйле аэростатлар күтәрүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына үзгәрешләр

1.1. 1.2.1. пунктында «дәүләт хакимияте органнарыннан тыш» сүзләреннән соң «, җирле үзидарә органнары» сүзләрен өстәргә.

1.2. «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр эчтәлеге» баганасының 1.4. пунктның 1 пунктчасында, 1.5. пунктында, 2.15. пунктында «Түбән Кама» сүзләрен «Түбән Кама муниципаль районы» сүзләренә алмаштырырга.

1.3. 1.6. пунктның 8 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «-Түбән Кама шәһәр Советының 2016 елның 14 апрелендәге 17 номерлы карары белән расланган Түбән Кама шәһәре Уставы белән».

1.4. 1.6. пунктның 7 һәм 10 абзацларын төшереп калдырырга.

1.5. 1.6. пунктына түбәндәге эчтәлекне абзац өстәргә: «Россия Федерациясе гражданнар авиациясендә очышлар әзерләү һәм башкару» Федераль авиация кагыйдәләрен раслау турында» Россия Транспорт министрлыгының 2009 елның 31 июлендәге 128 номерлы боерыгы белән».

1.6. «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.5. пунктындагы 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «һава судносын теркәү турындагы мәгълүматлар һава судноларына һәм алар белән алыш-бирешләргә хокукларның бердәм дәүләт реестрында булмаган очракта, һава судносына хокук билгеле торган документ.».

1.7 «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.6 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә: «һава судносына һава судноларына һәм алар белән алыш-бирешләргә хокукларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (мөрәҗәгать итүче тарафыннан һава судносына хокук билгеле торган документ тапшырылмаган очракта)».

1.8 «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.8. пунктындагы 2, 3, 4 пунктчаларын төшереп калдырырга.

1.9. «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.9. пунктына түбәндәге эчтәлекле сүзләр өстәргә:

«3) һава судноларына хокукларның һәм алар белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрыннан мөрәҗәгать итүченең һава судносына хокуклары булмау турында белешмәләр керү;

4) тапшырылган документларның әлеге регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве;

5) гаризада һәм гаризага теркәлеп бирелә торган документларда килешенмәгән төзәтмәләр, аларның эчтәлеген бертөрле аңлатырга мөмкинлек бирми торган җитди зыян бар;

6) тапшырылган документлар үз көчләрен югалттылар.».

1.10. «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.13. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гариза кергән көнне административ регламентның 3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә башкарыла.».

1.11. «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.14. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган урыннарга, мөрәҗәгать итүчеләрне көтү һәм кабул итү урынына, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итүгә, мондый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматлар урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә карата таләпләр».

1.12. «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.14. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә

«Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһаз, мәгълүмат такталары белән җиһазландырылган урыннарда һәм биналарда гамәлгә ашырыла.

Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керә алуы тәэмин ителә (уңайлы бинага керү-чыгу һәм алар чикләрендә күчү).

Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматлары мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.».

1.13. «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.15. пунктында «Түбән Каманың рәсми сайтында» сүзләрен «Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында» сүзләренә алмаштырырга.

1.14. 3.3.2 пунктында 4, 5 абзацларны төшереп калдырырга.

1.15. 3.3.2 пунктының 6 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:».

1.16. 3.4.1. пунктының 4 абзацында «әлеге регламентның 3.3.5. пунктында каралган процедураны тәмамлау» сүзләрен «Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты белгеченә документлар керү» сүзләренә алмаштырырга.

1.17. 3.5.3. пунктының 1 абзацында «Түбән Кама шәһәре» сүзләреннән соң «(6 нчы кушымта)» сүзләрен өстәргә.

1.18. 3.6.2. пунктының 2 абзацында «бирү» сүзе алдыннан «рөхсәт яки баш тарту турында хәбәрнамә» сүзләрен өстәргә.

1.19. 3.8.1. пунктының 5 абзацында, 5.2. пунктының 2 абзацында «Түбән Кама рәсми сайты» сүзләрен «Түбән Кама муниципаль районы рәсми сайты» сүзләренә алмаштырырга.